РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Чувашско-Бурнаевского
сельского поселения
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл Жирлеге
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422879 РТ, с. Чувашское Бурнаево, ул. Центральная, 25 а
тел: 8 (84346) 78-2-15

Адресы: 422879, РТ, Чуаш Борнае авылы, Үзәк ур. 25 а
факс: 8 (84346) 78-2-15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Чуаш Борнае авылы**

2023 нче елның 26 гыйнвар 2 №

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**Чуаш Борнае авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы "Җирләү һәм җирләү эше турында" 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә **7793,48** сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Чуаш Борнае авыл җирлеге башлыгы И.Г.Зарипов

Чуаш Борнае авыл җирлеге башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 2 № карарына 1 нче кушымта

Чуаш Борнае авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4489,06 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1621,04 |
| 4. | Җирләү (каберне казу һәм куму) | 1683,38 |
| | Барлыгы: | **7793,48** |

Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 26 гыйнварындагы 2 № карарына 2 нче кушымта

Чуаш Борнае авыл җирлегендә 2023 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү | 1497,12 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2985,70 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1621,04 |
| 5. | Җирләү (каберне казу һәм куму) | 1689,62 |
| | Барлыгы: | **7793,48** |